**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.58

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, ТР Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,58

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay.ispolkom@tatar.ru сайт:
www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

*2020 елның «3» ноябре* 445 №

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында спорт резервын әзерләүче физик тәрбия спорт оешмалары хезмәткәр - яшь белгечләренә акчалата түләүләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 31 октябрендәге «Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физик тәрбия спорт оешмалары хезмәткәр– яшь белгечләренә акчалата түләүләр билгеләү турында» 979 номерлы карарын үтәү йөзеннән, карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында спорт резервын әзерләүче физик тәрбия спорт оешмалары хезмәткәр - яшь белгечләренә кушымта нигезендә акчалата түләүләр бирү тәртибен расларга.

2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы мәгълүмати - хокукый ярдәм күрсәтүнең рәсми порталында» бастырып чыгарырга һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче: И. В. Юсупов

Татарстан Республикасы
Әлки районы Башкарма комитетының
2020 елның «3» ноябре 445 №
Карарына кушымта

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәр - яшь белгечләренә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының спорт резервын әзерләүче, гамәлгә куючы, функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасының Әлки районы Башкарма комитеты булган муниципаль физик тәрбия спорт оешмаларында (алга таба - оешмалар) эшләүче хезмәткәр - яшь белгечләргә түбәндәге акчалата түләүләрне бирүне билгели:

- ай саен эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә 1 111 сум күләмендә, әмма аена 1 111 сумнан артмаган стимуллаштыручы өстәмә түләү;

- 20 000 сум күләмендә хуҗалыкны төзекләндерүгә бер тапкыр түләнә торган акчалата түләү.

2. Оешма хезмәткәр-яшь белгечләренә акчалата түләүләр Татарстан Республикасы бюджетында Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына тиешле финанс елына каралган акчалар хисабына башкарыла .

3. Оешма хезмәткәр-яшь белгече дип беренче тапкыр көндезге формада һөнәри белем бирү оешмасын, югары белем бирү программалары - бакалавриат, специалитет, магистратура программалары буенча дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирү оешмасын (алга таба - һөнәри белем бирү оешмасы яисә югары белем бирүче мәгариф оешмасы) тәмамлаган, һөнәри белем дәрәҗәсе һәм квалификациясе нигезендә хезмәт шартнамәсе буенча һөнәри белем бирү оешмасын яисә югары белем бирү оешмасын тәмамлаган елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча оешмага түбәндәге вазифаларга эшкә алынган 30 яшькә(кертеп) кадәрле Россия Федерациясе гражданы танылa: физик тәрбия буенча инструктор, педагог-оештыручы, педагог-психолог, адаптив физик тәрбия буенча инструктор-методист, адаптив физик тәрбия буенча өлкән инструктор-методист, тренер, адаптив физик тәрбия буенча тренер-укытучы, хореограф, күнегүләр (тренировка) барышы (процессы) администраторы, адаптив физик тәрбия буенча өлкән тренер-укытучы.

4. Ай саен стимуллаштыручы өстәмә хезмәткәр - яшь белгечләргә эшкә урнаштыру аеннан соң килүче айның 1 числосыннан билгеләнә, әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган вазыйфада өзлексез эшләгән очракта, аны билгеләгән датадан беренче өч ел дәвамында түләнә.

Хезмәткәр - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүне билгеләү, туктату, озайту турындагы карар оешма боерыгы белән раслана.

Хезмәткәр - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү дәвам итә:

Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә чакырылыш буенча хезмәт итү яки альтернатив граждан хезмәте чорында;

йөклелек һәм бала табу буенча отпуск, өч яшькә җиткәнче бала карау буенча отпуск чорында;

көндезге формада аспирантурада уку чорында.

5. Хезмәткәр - яшь белгеч башка оешмага аналогик вазыйфага күчкәндә, 30 көннән дә артмаган тәнәфес рөхсәт ителә.

6. Хезмәткәр - яшь белгечне алга таба башка оешмага аналогик вазыйфага эшкә урнаштырып, сан яки штат кыскаруга бәйле рәвештә эштән чыгарганда 60 көннән дә артмаган тәнәфес рөхсәт ителә.

7. Хезмәткәр – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү яшь белгечнең төп эш урыны буенча гына билгеләнә.

8. Хезмәткәр – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү төп хезмәт урыны буенча һәм әлеге хезмәткәр – яшь белгеч тарафыннан бер оешмада ике эшне башкару шартларында гамәлгә ашырылган вазыйфа буенча, ләкин 1 ставкадан артмаган күләмдә билгеләнә.

9.ай саен эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә 1 111 сум күләмендә, әмма аена 1 111 сумнан артмаган стимуллаштыручы өстәмә түләү; Ай саен 1111 сум күләмендә түләнүче стимуллаштыручы өстәмә эшләнгән вакытка пропорциональ, әмма аена 1111 сумнан да артмый.

10. Хуҗалык төзеклəндерүгə түлəнə торган акчалата түлəү хезмəткəргə бер тапкыр гына бирелə.

11. Хезмәткәр Министрлык раслаган форма буенча, һөнәри белем бирү оешмасы яки югары белем бирүче мәгариф оешмасы тәмамлаганнан соң эшкә урнашкан оешмада эшли башлаганнан алып ике ел дәвамында

оешма җитәкчесе исеменә хуҗалык төзекләндерүенә бер мәртәбә акчалата түләү билгеләү турындагы гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы

12. Оешма ай саен, агымдагы айның 5 числосына кадәр, Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра: - Министрлык тарафыннан расланган форма буенча акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга акча бирү турында мөрәҗәгать;

- оешма хезмәткәр – яшь белгечләренең Министрлык әмере белән расланган форма нигезендә реестрлары.

13. Министрлык әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән документларны, алар кергән көннән эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек срокта карый.

Оешма әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган пакетын яки югарыда аталган пункт таләпләренә туры килми торган документларны тапшырган очракта, Министрлык гаризаны кире кайтара һәм биш көн эчендә оешмага, кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, хәбәр итә.
Гаризаны кире кайтару турында хәбәрнамә алынган көннән оешма әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән документларны әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәп кабат тапшыра.

14. Хезмәткәр - яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга оешма чыгымнарын финанс белән тәэмин итү Министрлык тарафыннан әлеге максатларга оешмага субсидияләр бирү юлы белән гамәлгә ашырыла. Субсидия Министрлык һәм оешма арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган типлаштырылган форма буенча төзелә торган килешү (алга таба - Килешү) нигезендә бирелә.
Килешү әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырганнан соң 10 көн эчендә төзелә.

15. Министрлык ай саен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган оешмаларның шәхси счетларына эшләүче хезмәткәр - яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру өчен субсидияләр бирә.

16. Оешмалар, Килешүдә каралган сроклар һәм форма нигезендә, хезмәткәр - яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру өчен субсидияләрдән файдалану турында Министрлыкка хисап тапшыралар.

17. Агымдагы финанс елында оешма тарафыннан файдаланылмаган субсидияләр Татарстан Республикасы бюджетына билгеләнгән тәртиптә күчерелергә тиеш.

18.Оешма тарафыннан субсидияләр бирү шартлары бозылганда, Министрлыкның язма таләбе нигезендә субсидияләр тиешле таләп алынган көннән алып 10 эш көне эчендә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиеш.

19. Субсидияләр бирү шартларын, шулай ук төзелгән килешүләрнең үтәлешен контрольдә тоту Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан башкарыла.

20. Оешма хезмәткәр - яшь белгечләргә оешма билгеләгән хезмәт хакын түләү срокларында акчалата түләүләр бирүне тәэмин итә.